ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме дүртенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме дүртенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында.
4. Татарстан Республикасы Иннополис шәһәре территориясендә югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган транспорт чараларын эксплуатацияләү буенча цифрлы инновацияләр өлкәсендә эксперименталь хокукый режим урнаштыру мөмкинлеге турында.
5. Торак шартларын яхшыртуга ана (гаилә) капиталы акчаларын (акчаларның өлешен) җибәрү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү кирәклеге турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате хакында.
6. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 210-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредиты бирү турында 2020 елның 14 декабрендәге 01-01-06/06-1022 номерлы килешүгә 2021 елның 1 июлендәге 1 номерлы өстәмә килешүне раслау хакында» 222-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 212-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 213-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 223-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының $6^1$ һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 211-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 220-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 217-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 214-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 218-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 221-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 207-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 219-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 215-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

20. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 226-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

21. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 200-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

22. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 216-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

23. «2022 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 224-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

24. «2022 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 225-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

25. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1219893-7 номерлы федераль закон проекты турында (янгыннан саклау бүлекчәләренең эшчәнлеген камилләштерү өлешендә).

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1221704-7 номерлы федераль закон проекты турында (Кодекс нигезләмәсен кыйммәтле металлар һәм асылташлар турында Россия Федерациясе законнарына туры китерү өлешендә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
урынбасары

Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2021 елның 16 сентябре
№ 1067-VI ДС